ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ПОЛЯНКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАР

№ 53-3 06.03.2023 ел.

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Полянка авыл җирлеге Советының 2021 елның 24 сентябрендәге 24-4 номерлы карары (2021 елның 07 декабрендәге 30-1 номерлы үзгәреш белән, 2022 елның 01 апрелендагы 37-1 номерлы; 2023 елның 30 гыйнварындагы 50-2 номерлы) белән расланган Полянка авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә Бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 72 статьясы нигезендә, «Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 29 декабрендәге 521-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Полянка авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Әҗмәр авыл җирлеге Советының 2021 елның 24 сентябрендәге 24-4 номерлы карары (2021 елның 07 декабрендәге 30-1 номерлы үзгәреш белән, 2022 елның 01 апрелендагы 37-1 номерлы; 2023 елның 30 гыйнварындагы 50-2 номерлы) белән расланган Әҗмәр авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә Бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 13 статьясын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13 статья муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуны гамәлгә ашыру.

1. Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә, РФ Бюджет кодексы нигезләмәләрен исәпкә алып, дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә гамәлгә ашырыла.

2. Муниципаль контрактлар, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 72 статьясындагы 3 пунктында билгеләнгән очраклардан тыш, бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә төзелгән һәм расланган муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр закупкаларының план-графигы нигезендә төзелә һәм түләнә.»

1.2. 45 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Бюджет акчаларын алучы бюджет йөкләмәләрен кабул итә һәм аңа кадәр җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә элек кабул ителгән бюджет йөкләмәләренә үзгәрешләр кертә.

Бюджет акчаларын алучы бюджет йөкләмәләрен дәүләт (муниципаль) контрактлары, физик һәм юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр белән башка килешүләр төзү юлы белән яки закон, башка хокукый акт, килешү нигезендә кабул итә.

Бюджет акчаларын алучы бюджет йөкләмәләренең тиешле лимитлары һәм кабул ителгән, әмма үтәлмәгән бюджет йөкләмәләре арасындагы аермадан артмаган күләмдә яңа бюджет йөкләмәләрен кабул итә.

Бюджет акчаларын алучы муниципаль контрактларны, мондый муниципаль контрактлар, бюджет йөкләмәләренең расланган лимитларының гамәлдә булу срогы чикләрендә мондый муниципаль контрактлар буенча йөкләмәләрне үтәүне күздә тота торган башка килешүләрне, Бюджет кодексы һәм бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган башка федераль законнар нигезләмәләрендә каралган очракларда төзи. Муниципаль контрактлар, башка килешүләр төзү өчен билгеләнгән күрсәтелгән нигезләмәләр элегрәк төзелгән муниципаль контрактларга, башка килешүләргә үзгәрешләр кертелгәндә дә кулланыла.

2. Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында http:/ www.spasskiy.tatarstan.ru, хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (//http:pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Полянка авыл җирлеге башлыгы А.Ю.Царев

СОВЕТ ПОЛЯНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «ПОЛЯНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН